Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Казак Чаллысы авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 3**

Казак Чаллысы ав. 2019 елның 2 апреле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Казак Чаллысы авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешмалар белән (сәяси фиркадән гайре) бер үзе башкарма орган сыйфатында идарә итүдә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүенә рөхсәтен алу тәртибе турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казак Чаллысы авыл җирлеге Советының 2017 елның 22 августындагы 8 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, 2018 елның 3 августындагы “Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 340-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Казак Чаллысы авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешмалар белән (сәяси фиркадән гайре) бер үзе башкарма орган сыйфатында идарә итүдә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүенә рөхсәтен алу тәртибе турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казак Чаллысы авыл җирлеге Советының 2017 елның 22 августындагы 8 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Казак Чаллысы авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең түләүсез нигездә

коммерциячел булмаган оешмалар белән (сәяси фиркадән гайре) бер үзе башкарма орган сыйфатында идарә итүдә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүенә рөхсәтен алу тәртибе турында Нигезләмәнең 1 пунктында "җиләк-җимеш, яшелчә бакчачылыгы, дача кулланучылар кооперативы," сүзләрен төшереп калдырырга

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казак Чаллысы авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Казак Чаллысы авылы, Иванов урамы, 26 йорт; Иванаево авылы, Калинин урамы, 18 йорт; Үри Чаллысы авылы, Гаврилов урамы, 24 йорт; Бирдебәк авылы,Мәктәп урамы,4 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Казак Чаллысы авыл җирлеге башлыгы И.С.Ананьев